РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
БОЛЬШЕФРОЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ФРОЛОВО
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«16» ноябрь 2020 ел № 2-5

2019 елның 23 октябрендәге 77-1 номерлы
Зур Фролово авыл Советы карарына үзгәрешләр
кертү турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зур Фролово авыл Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 октябрендәге 77-1 номерлы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Буа муниципаль районы Зур Фролово авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

I. Зур Фролово авыл Советының 2019 елның 23 октябрендәге 77-1 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына (2020 елның 02 мартындагы 84-2номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 статьяның 1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,1 %ы;».

II. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

III. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http//buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

ТР Буа муниципаль районы
Зур Фролово авыл җирлеге башлыгы О.Г. Масленцева